Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

"Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең 2019 елның 3 июнендәге 4 номерлы «Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә хакында" карарына үзгәрешләр кертү турында

№ 1 “17” май 2021 ел.

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең 2019 елның 3 июнендәге 4 номерлы «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә турында" гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 34 бүлегендәге 4 пунктта "(булганда), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен" сүзләрен өстәргә.

1.2 19 Бүлегендәге 3 пунктның 4 пунктчасында "хезмәт кенәгәсе" сүзләреннән соң "һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр" сүзләрен өстәргә";

1.3 19 бүлегендәге 3 пунктның 6 пунктчасы "мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы" сүзләрен "индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ" сүзләренә алмаштырырга.

1.4 3 өлешнең 15 статьясына түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.»

2.Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Башлык М. М. Боков